## *ПРОБЛЕМАЛЫ ДӘРЕСНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ*

**М. МӘХМҮТОВ,**

СССР Педагогия фәннәре академиясенең член-корреспонденты

## I. ПРОБЛЕМАЛЫ ДӘРЕСНЕҢ ЭЧКЕ ТӨЗЕЛЕШЕ

Мәктәптә укыту-тәрбия эшен оештыруның төп формасы — дәрес, диелә гомуми урта белем мәктәбе Уставында. Шуның белән бергә, һәр дәрес укыту процессының аерылгысыз өлеше, һәм ул шушы процессның барлык билгеләрен үзендә берләштерә.

Традицион укытуда күпчелек укытучылар һәрвакыт дүрт элементтан (этаптан) торган (үткән материалны кабатлау, яңа материалны аңлату, аны ныгыту һәм өйгә эш бирү) катнаш (комбинированный) дәрес белән чикләнделәр. Инде расланганча, дәрес структурасын шулай аңлау һәм укытуда гел шундый гы«а структура куллан/ укытучыларның иҗади мөмкинлекләрен чикләде һәм барлык укыту процессын һаман үзгәрешсез, бер төстә оештыруга китерде.

Дәреснең күп проблемаларын хәл итүнең иҗади юлларын эзләү һаман дәвам иттерелсә дә, аның табигате совет педагоглары тарафыннан яхшы тикшерелгән. Дәресләрнең төп типларын аерым-аерым күрсәтүгә һәм аларның структурасын бәян итүгә дидактика зур әһәмият биреп килде. Укытуның дидактик максатларына, эчтәлегенә һәм методларына бәйле рәвештә, дәресләрнең күптөрле типологиясе һәм методик вариантлары эшләнгән. Мәсәлән, С. Г. Шаповаленко һәркайсының икедән алып бишкә кадәр варианты мөмкин булган биш төрле дәрес тибын тасвирлый[1]. Алар түбәндәгеләр:

1. Укытуның барлык бурычлары гамәлгә ашырыла торган дәресләр.
2. Яңа материалны зиһенгә алу һәм башлангыч үзләштерүне төп

---

[1] Кара: С. Г. Шаповаленко. Методика обучения химии в восьмилетней школе, 321—328 нче битләр.

бурыч итеп куйган дәресләр.

3. Алган белемнәрне ныгыту һәм кабатлау, эшли белү осталыгы һәм күнекмәләр булдыру максаты белән уздырыла торган дәресләр.

4. Мөстәкыйль эшләр, теоретик һәм практик биремнәр үтәгәндә элек үзләштерелгән белемнәрне кулланырга өйрәнү максатын алга куеп уздырыла торган дәресләр.

5. Кабатлау-гомумиләштерү, укучыларның белемнәрен тикшерү һәм системага китеру максаты белән үткәрелә торган дәресләр.

Китерелгән дәрес типлары, нигездә, традицион укытуга хас.

Мәгълүм ки, дәреснең тибы аның төп юнәлешен генә билгели. Дәресне характерлаучы иң әһәмиятле нәрсә — «аның структурасы, структура дәрестә укыту процессының логикасын һәм аның этаплары һәм звенолары эзлеклелеген чагылдыра»[2].

Укыту процессын активлаштыруның теоретик һәм практик юлларын эзләү барышында дәреснең структурасы һәм аның асылы турында бер-берсенә капма-каршы фикерләр әйтелде. Аларның киң таралганнары дүртәү:

а)структурасы дүрт элементтан торган катнаш дәреснең универсаль әһәмияткә ия булуын раслау;

б)катнаш дәрес урынына «этапсыз структуралы» (К. А. Москаленко) берләштерелгән дәрес куллану;

в)укыту процессында куп типлы һәм структуралы дәресләр «иң урын алырга тиеш;

г) дәреснең структурасы укыту процессында зур урын тотмый, аның .структурасын алдан эшкәртеп кую укытучының дәрестә иҗади эшләвенә комачаулый.

Әмма алдынгы практика дәрес структурасының әһәмияте зур һәм аны куллану дәресне фәнни оештырырга мөмкинлек бирүче категория булуын күрсәтте. Алдынгы укытучылар тәҗрибәсендә укучыларның дәрестә танып-белү эшчәнлеген тагын да нәтиҗәлерәк итеп оештыруның төп билгеләре ачыкланды. Соңгы елларда дәрес этапларында да, материалны өйрәтү логикасында да үзгәрешләр барлыкка килде, мәсәлән, яңа материалны үзләштерү элек узылган материалны кабатлау белән бер вакытта алып барыла башлады. Белемнәрне үзләштерү белән аларны ныгыту бер бөтен процесска әйләнде. Бу өлкәдәге тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр ачыкланды: «дәреснең укытучы алдан билгеләгән

[2] «Урок в восьмилетней школе», 172 нче бит.

бурычлары да, эчтәлеге дә, дәрестә тормышка ашырыла торган укыту процессы логикасы да, дәреснең структурасы да, укыту методлары да — боларның һәммәсе дә укучыларның дәрестә тырышып эшләүләренә һәм уку процессыннан канәгатьләнү хисе алуларына юнәлдерелергә тиеш»[3].

М. Н. Скаткинның «Хәзерге заман дәресләренә таләпләр» исемле хезмәтендә укучыларның актив танып-белү эшчәнлеген тәэмин итәргә тиешле дәресне оештыруның төп кагыйдәләре *бәян* ителә. Автор, «дәреснең структурасы таркау, эшләнмәгән һәм очраклы була алмый»[4], дип басым ясап әйтә.

Безнең мәкаләдә проблемалы дәреснең типлары һәм структурасы мәсьәләсе карала. Әгәр **дәреснең методик варианты** аны оештыруның методлары (беседа-дәрес, сочинение-дәрес һ. б. ш.) белән билгеләнсә, ә **типлары** дидактик максатларга, укытуның эчтәлегенә һәм методларына (яңа белемнәр үзләштерү дәресләре, белемнәрне кабатлау һәм ныгыту дәресләре һ. б. ш.) бәйле булса, **аның структурасы** исә укыту процессының логикасы, аның топ этапларының (звеноларының) эзлеклелеге белән билгеләнә.

Югарыда дәреснең төрле этапларының үзара бергә кушылып бер бөтен тәшкил итүе һәм аларның функциональ әһәмияте үзгәрүе турында әйтелде инде. Безнең күзәтүләр санап узылган дәрес типларының проблемалы укыту процессында бер бөтен булып берләшүләрен тагын бер талкыр раслый. Мәсәлән, кабатлау-гомумиләштерү һәм укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен тикшерү һәм анализ ясау дәресләре аерылгысыз бердәмлектә үткәреләләр, аларның максаты бер типтагы дәрестә тормышка ашырыла (аерма аның методик вариантында гына булырга мөмкин). Әйтик, проблемалы теләсә нинди дәрестә диярлек яңа белемнәрне үзләштерүгә дә, үткән материалны кабатлау һәм ныгытуга да, белемнәрне тормышта куллануга карата да мөстәкыйль эшләр бирелә. Шунлыктан проблемалы укыту өчен, башлыча, ике тип дәрес хас.

1. Проблемалы дәреснең беренче (төп) тибы. Бу тип дәрестә: а) яңа материал үзләштерелә, б) белемнәр ныгытыла, *в)* белемнәр өйрәнү-практик һәм теоретик характердагы мөстәкыйль эшләрне үтәү барышында кулланыла. Яңа материалны үзләштерү, аны ныгыту һәм алган белемнәрне практикада куллану проблемалы дәреснең төп тибына керә, чөнки укыту процессының бу өч этабы, кагыйдә буларак, бердәм процесс.

Ләкин, материалның эчтәлегенә һәм дидактик максатка бәйле рәвештә,

---

[3] Шунда ук, 172 нче бит.
[4] *М. Н.* Скаткин. Требования к современному уроку, 140 нчы бит.

белемнәрне үзләштерү һәм укучыны акыл эшчәнлеге операцияләренә (фикерләү ысулларына) өйрәтү процесслары төрле фазаларга бүленә һәм махсус күнегүләр таләп итә. Шунлыктан проблемалы укыту икенче тип дәресләрне дә эченә ала.

2. Икенче типка: а) төрле-төрле мөстәкыйль эшләр башкару юлы белән күнекмәләр формалаштыру яки б) кабатлау-гомумиләштерү, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен системага салу һәм тикшерү дәресләре керә.

Икенче тип дәрес тышкы яктан традицион катнаш дәресләрне хәтерләтсә дә, эчке яктан ул аңардан сизелерлек аерыла. Чөнки укучының төп тип дәресләрдә формалаша торган танып-белү эшчәнлеге структурасы укыту процессының барлык соңгы звеноларында өстенлек ала, аның ахыргы этапларына тәэсир итә. Бу структура кабатлауга, системалаштыруга һәм күнекмәләр булдыруга карата бирелгән мөстәкыйль эшләрдә проблемалы ситуация булу белән аерылып тора, һәм ул проблемалы дәресләрнең икенче тибы өчен хас.

Проблемалы дәресләрнең шушы ике тибы дидактик максатларга, укыту материалының эчтәлегенә, укыту методларына, укучыларның хәзерлек дәрәҗәсенә, дәреснең дидактик җиһазлануына һ. б. бәйле рәвештә барлыкка килгән күптөрле методик вариантларның барсын да үз эченә ала.

Проблемалы дәреснең структурасы нидән гыйбарәт соң? Аның структурасы бердәнберме, әллә берничәме? Моңа җавап бирергә тырышучылар булмады түгел, булды инде. Польша дидакты Э. Флеминг, мәсәлән, үзенең хезмәтләрендә дәреснең структурасы белән укучыларның танып-белү эшчәнлеге этаплары арасында бердәмлек булу идеясен үткәрә. Ул проблемалы дәрес структурасын эшкәртүнең түбәндәге принципларын китерә: а) материалның күләмен һәм сыйфатын билгеләү; б) укыту предметы логикасына туры китерел, материалны системага салу; в) материалны җиңел аңлашылырлык итеп өлешләргә бүлү; г) әлеге элешләрне укучыларның үзләштерүенә укытучы җитәкчелегендә һәм аның ярдәмендә ирешү; д) үзләштерүнең индивидуаль темпларын исәпкә алу.

Ләкин Э. Флеминг тәкъдим итә торган дәрес структурасы проблемалы укытуны оештырганда без күз алдында тота торган дөрес структурасына тулысынча туры килеп җитми.

Проблемалы дәрес структурасын билгеләү нияте белән, 1967 нче елда безнең тарафтан бер фикер әйтелгән дә иде инде. Аерым алганда, ул вакытта алдынгы укытучыларның практикасында экскурсия-дәрес, диспут-дәрес, семинар-дәрес һ. б. ш. дәресләрнең ешрак күренүе, дәреснең традицион (электән кулланылган) структурасы эчендә яңа элементлар шәйләнүе, шулар-ның нәтиҗәсе буларак,

дəреснең яңа структурасы барлыкка килүе күрсəтелде[5].

Безнеңчə, дəрес структурасын төзүнең төп принциплары түбəндəгелəр: укыту процессының логикасы, белемнəрне проблемалы үзлəштерү, аларны ныгыту һəм килəчəктə ул белемнəрдəн өйрəнү-практик һəм теоретик эшчəнлектə куллану процессында укытучы һəм укучыларның эшчəнлек этаплары.

Проблемалы дəреснең структурасы, безнеңчə, түбəндəге элементларны эченə ала:

1)Элек үзлəштерелгəн белемнəрне һəм күнекмəлəрне актуальлəштерү (яңа белемне үзлəштерү өчен кабатланган элекке белемнəр).

2)Проблемалы ситуация тудыру һəм проблемалар кую.

3)Эзлəнү һəм проблеманы хəл итү (гипотезалар кую һəм аларны исбатлау).

4)Проблеманы хəл итүнең дөреслеген тикшерү һəм кирəкле очракларда аны хəл итүнең барышын кабатлау.

Проблемалы дəреснең беренче элементы үзенең эчтəлеге белəн аңлатмалы-иллю-стратив укыту өчен хас булган катнаш дəреснең сорау-җавап этабына якын тора. Əмма аның үзенчəлеге дə бар. Мəгълүм булганча, сорау-җавап этабы үз алдына ике максат куя: а) үткəн дəрестə үзлəштерелгəн белемнəргə контроль ясау, б) өйрəнгəн материалны кабатлау һəм яна белемнəрне үзлəштерүгə укучыларны хəзерлəү.

Проблемалы укытудагы беренче этап (актуальлəштерү этабы) исə өч максатны күздə тота һəм алар традицион сорау-җавап этабының максатларыннан түбəндəге сыйфатлар белəн аерылалар: а) үткəн материалның яңа бирелəчəк белемнəргə ту-рыдан-туры бəйле булганнары тулысынча искə төшерелə, проблемалы ситуация тудыруга яки башта куелган проблеманы хəл итүгə хəзерлек алып барыла, б) элек үзлəштергəн акыл һəм практик эшчəнлек-лəрнең алымнарын тикшерү, в) элек үзлəштерелгəн белемнəрне практикада куллану (бу очракта «практикада куллану» дигəннəн без укучыларның уку заданиелəрен үтəү буенча өйрəнү-практик һəм теоретик төстəге эшлəрен, аерым алганда, элек алган белемнəрен яңа белемнəрне үзлəштерү өчен файдалануны күз алдында тотабыз).

Проблемалы дəрес, кагыйдə буларак, традицион сорау-җаваптан (ягъни үткəн дəрес материалын кабатлаудан) түгел, бəлки булган белемне (хəтерлəтүне дə, элек өйрəнелгəн кагыйдəлəрне (мəсəлəн, проблеманы хəл итү алымнарын) куллануны да талəп итүче мөстəкыйль эшлəрдəн башлана.

---

[5] М. И. Махмутов. Проблемное обучение в опыте передовых учителей Татарии, 2 нче бит.

Проблемалы дәрес структурасының икенче элементы—проблемалы ситуацияләр тудыру (укытучы тудыра) һәм проблемалар кую (укытучы да, укучылар да куя ала). Әгәр дәреснең максаты яңа белемнәр үзләштерү икән, ул чагында дәреснең икенче элементы, башлыча, яңа укыту материалын укытучының проблемалы бәян итүе (проблемное изложение) һәм укучының мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеген оештыруы белән билгеләнә. Дәреснең икенче элементы укучының мөстәкыйль эшчәнлеген чагылдыручы өченче элемент белән бик тыгыз бәйләнә. Дәрес структурасындагы икенче элементының төп эчтәлеге — проблемага якынлашу, аңа формулировка бирү (аны сүз белән аңлату) яки шул формулировканы икенче төрле, башка җөмлә белән әйтү. Мәсәлән: «Туры сөйләмнән башка тагын нинди сөйләм була?» Шул ук сорауның эчтәлеген ачыт бирә торган икенче җөмлә дә төзеп була, әйтик: «Нинди сөйләм кыек сөйләм дип атала?»[6].

Әгәр дәреснең максаты кабатлау, элек үзләштерелгән белемнәрне һәм күнекмәләрне ныгыту яки белемнәрне практикада кулланырга өйрәтү булса, ул чагында дәреснең икенче элементы уку-укыту проблемаларын эченә алган мөстәкыйль эшләр, төрле күнегүләр һ. б. системасын оештыр/ белән билгеләнә.

Проблемалы дәреснең өченче элементы бөтенләе белән диярлек икенчесе белән берләшә. Аның эчтәлеген проблеманы хәл итү, уку-укыту проблемасын анализлау, фикерләр әйтү, гипотезаларны нигезләү һәм аларны исбатлау буенча укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге тәшкил итә. Икенче төрле әйтсәк, өченче элемент — мөстәкыйль эшләрне һәм төрле биремнәрне үтәү буенча укучыларның эшчәнлеге ул.

Бу әһәмиятле этапта укучылар яңа белемнәр һәм яңа күнекмәләр үзләштерәләр, аларны ныгыталар, үзләштерелгән белемнәрне яңа ситуациядә (мәсәлән, санлы, яңа мәгълүматлар белән типик мәсьәләләр чишкәндә) кулланырга өйрәнәләр. Шунда ук яңа белемнәрнең үзләштерелүенә һәм нык-лыгына контроль дә ясала.

Проблемалы дәрес структурасының **дүртенче** элементы — уку-укыту проблемасыз хәл итүнең дөреслеген тикшерү һәм белемнәрне үзләштерү барышына укытучының (укучының да) контроль ясавы. Бу процесста укучылар хаталарын төзәтәләр, проблеманы хәл итүнең төрле вариантларының кайсысы

---

[6] Журналның шушы санындагы туры һәм кыек сөйләм турындагы мәкаләне карагыз, 25 нче бит.

нәтиҗәле булуын исбат итәләр, мөстәкыйль эшләрне башкарганда үзләре чыгарган сөземтәләрне кулланып, нәтиҗәләрне тикшерәләр һ. б.

Укыту проблемасын хәл итүнең бөтен барышы кабатлау — узылганнарга анализ ясау һәм хәл итүнең оптималь вариантларын эзләү формасын ала. Ул хәл итүнең яңа ысулын куллану күнекмәсен эшкәртү, үзләштерелгән белемнәрне һәм күнекмәләрне ныгыту алымы булып та тора.

Югарыда бәян ителгәннән күренгәнчә, проблемалы дәреснең структур элементлары проблемалы укыту процессы логикасы һәм укучыларның иҗади танып-белү эш-чәнлегенең этаплары белән зарури бәйләнештә булалар. Дәреснең шушы гомуми-ләштерелгән структурасы цикләрендә аның конкрет вариантлары да булырга мөмкин. Әгәр, мәсәлән, укытучы дәреснең башында ук проблемалы ситуация тудырса һәм материалны укучыларга анализ өчен (яки күр-сәтмәлелек өчен) бирсә, дәрес структурасының беренче элементы (актуальләштерү) аның икенче элементы булып та килә ала. Проблема кую белән аны чишү арасында актуальләштерү дәреснең өченче элементының өлеше булып китүе дә ихтимал.

Дәреснең аерым этапларында пробле-малылыкның дәрәҗәсенә бәйле рәвештә проблемалы дәреснең структурасы аерым этапларда үзгәрү ихтималы бар. Әгәр укытучы бер үк дәрестә берничә проблемалы ситуация тудырса, өч элементның һәркай-сының үз эчендә кечкенә-кечкенә структуралар барлыкка килә. Мәсәлән, беренче этаптагы (беренче элементтагы) төп (катлаулы) проблемада шул этапта ук хәл ителүче ярдәмче проблема да (подпроблема) куела ала. Ул чагында дәреснең икенче этабы яңадан ярдәмче проблема куюдан, аны хәл итү юлларын эзләүдән һәм аны хәл итүдән башланып китәргә тиеш була. Икенче төрле әйтсәк, .күрсәтелгән проблема билгеле цикләр арасында үзгәреп, алма-шынып тора һәм дәреснең буеннан-буена да, 'аның аерым звеноларына да хезмәт күрсәтә.

Проблемалы дәрес структурасы шулай ук белемнәрне ныгыту белән бәйле булган билгеле бер звеноларны да, укыту процессының аерылгысыз өлеше булган күнекмәләр булдыру буенча төрле күнегүләрне дә эченә ала.

## II. ПРОБЛЕМАЛЫ ДӘРЕСКӘ ӘЗЕРЛӘНҮ

Педагогларның күбесе дәрескә әзерләнүне укыту процессын оештыруның әһә-миятле шарты итеп саныйлар. Дәрескә әзерләнү — тәҗрибәле укытучы өчен дә

катлаулы эш, чөнки ул аннан иҗади эзләнү таләп итә.

Дәрескә әзерләнүдә укытучы өчен төп кыенлык нәрсәдә? Дәрескә әзерләнгәндә ул вакытын күбрәк нәрсәгә сарыф итә? Беренче кыенлык барлык укучыларның де программа материалын дәрестә үк үзләштерүләренә ирешүгә генә түгел, бәлки дәресне аларның фикерләү сәләтләрен һәм мөстәкыйль танып-белү эшчәнлекләрен үстерүне дә тәэмин итәрдәй итеп оештыру алымнарын һәм укыту методларын эзләү белән бәйле. Икенче кыенлык — дидактик материаллар, ягъни төрле төстәге мәсьәләләр, иҗади эшләү өчен тормыштан алынган биремнәр, укучыларның актив эшчән-легенә исәп тоткан күрсәтмә әсбапларның җитү-җитмәвендә. Кыенлыкларның өченчесе — проблемалы дәресләрдә индивидуальләштереп укыту зарури булуда.

3. И. Романовская үзенең дәрескә әзерләнү турындагы хезмәтендә [7] бу кыенлыкларның кайбер сәбәпләрен дөрес күрсәтә. Беренчедән, хәзер укыту процессында укытучы белән укучы эшчәнлегенең нисбәте үзгәрде, бу алар арасындагы мөнәсәбәтнең яңа структурасын эзләргә мәҗбүр итте. Безнең көннәрдәге дәресләрдә мәктәп балаларының мөстәкыйль танып-белү эшчән-легенең күләме артты, ә укыту процессының материаль базасы (укыту әсбаплары, күрсәтмә-иллюстратив материал) искемә диярлек калды. Хәзер укыту материалының дәрестә элеккегә караганда күбрәк узылуын да әйтергә кирәк. Безнең көннәрдәге укучылар өйрәнү-практик эшләр белән күбрәк шөгыльләнәләр: күбрәк язалар, күбрәк саныйлар, мәсьәләләрне күбрәк чишәләр, тәҗрибәләрне дә элеккедән күбрәк ясыйлар һ. б. Шуңа карамастан, укытучы кулында булган күрсәтмә материал күпчелек очракларда аңлатмалы-иллюстратив укытуга исәпләнгән һәм алар укучыларның актив мөстәкыйль эшләүләренә бик аз ярак-лаштырылганнар.

Икенчедән, дәрескә әзерләнүдәге кыенлык тагын укытучының эш практика-сында хезмәтне фәнни оештыруның (НОТ) хәзергә урын алмавы белән дә аңлатыла. Укытучы еш кына дәресләргә җентекләп әзерләнергә өлгерә алмый, һәм ул аларны төрле дәрәҗәдә үткәрә. Шунлыктан, аерым дәресләрне уңышлы гына үткәрсә *дә,* үзенең эшендә даими яхшы нәтиҗәгә ирешә алмый. Өченчедән, дәреслекләрдә материал (хәтта яңа программалар белән тө-зелгәннәрендә дә) информацион төстә бәян ителгән. Аларны проблемалы сораулар һәм мәсьәләләр рәвешенә укытучы үзе китерергә һәм теге яки бу теоретик курсны өйрәнгәндә

---

[7] 3. И. Романовская. Подготовка учителя к урокам. «Урок в восьмилетней школе» исемле китапның 214—242 нче битләре

техник чаралар куллану мөмкинлеген үзе эзләп табарга мәҗбүр була. Шушылардан чыгып, дидактика алдына, уку һәм танып-белү процессын активлаштыруның юлларын эзләү белән бер үк вакытта, проблемалы дәресләргә әзерләнүнең фәнни нигезләнгән алымнарын булдыру бурычы килеп басты.

Педагогик әдәбиятта дәрескә әзерләнүнең билгеле бер системасы булырга тиешлеге әйтелә. Аның кирәклеге укытучыларның алдынгы тәҗрибәсе белән дә раслана. Бу система нинди соң? Укытучы кулында ул нәтиҗәле чара була алырмы?

Кайбер авторлар (С. И. Иванов һәм З. И. Романовская), укытучының дәрескә әзерләнү системасына түбәндәгеләр керергә тиеш, дип саныйлар.

1) Уку елына хәзерлек;
2) дәресләр системасын темалар буенча планлаштыру;
3) аерым дәресләргә әзерләнү.

Дөрес, бу системаның элементлары һәр укытучының практикасында бар, шуның белән бергә, аларкың эчтәлеге һәм үзара мөнәсәбәте һәр укытучыда төрлечә. Ләкин бу система бик гомуми һәм кимчелекле. Шунлыктан ул дәрескә уңышлы әзерләнүне тәэмин итә алмый.

Проблемалы дәрескә әзерлекнең системасы нинди булырга тиеш? Бу сорауга Т. В. Кудрявцев җавап бирмәкче була һәм дәрескә әзерләнүнең түбәндәге схемасын тәкъдим итә:

1) Материалның эчтәлегенә анализ ясау һәм, шуннан чыгып, 2) проблемалы ситуацияләрнең типларын сайлап алу; 3) укыту материалын проблемаларның типлары һәм дәреснең структурасына бәйле рәвештә төзү; 4) дәреснең барышын алдан күз алдына китерү [8].

Каралган схеманы бөтенләе белән читкә какмыйча, аның проблемалы дәреснең барлык таләпләрен дә тулысынча канәгатьләндерә алмавын әйтергә кирәк, чөнки ул бөтен бер система тәшкил итми.

Укыту материалына анализ ясаганда, беренче нәүбәттә, аның иң әһәмиятле өлешләрен, үз предметының аеруча гомумирак төшенчәләрен аерып алучы һәм икенче дәрәҗәдәге (аерым) төшенчәләрне билгели белүче укытучылар алдынгы тәҗрибәдә яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр. Алар, катлаулырак төшенчәләрне барлык укучылар да аңларлык итеп, һәр дәресне һәм дәресләр системасын алдан .планлаштыралар, ул төшенчәләрнең асылын ачуга күбрәк вакыт калдыралар,

---

[8] Т. В. Кудрявцев. Вопросы психологии и дидактики проблемного обучения, 19 нчы бит.

аларны ныгытуга күбрәк күнегүләр ясаталар. Шулай да, дәрескә әзерләнүнең билгеле бер фәнни системасы булганда гына, дәрес уңышлы булыр дип өметләнергә мөмкин.

Безнең тикшеренүләр укыту материалын анализлауның һәм дәрескә әзерләнүнең түбәндәге системасы проблемалы дәресләрнең нәтиҗәле булуына китерүен күрсәтә:

а) укыту материалына фәнни анализ ясау;

б) логик анализ ясау;

в) психологик анализ ясау;

г) дидактик анализ ясау;

д) укыту материалының тәрбияви әһәмиятенә анализ ясау.

Хәзер инде, проблемалы дәресләрнең төп тибына әзерләнү күзлегеннән чыгыл, шушы системаның һәр элементына аерым-аерым тукталып узыйк.

**1.Фәнни анализ.** Укыту материалына фәнни анализ ясау — барыннан да бигрәк белемнәрнең эчтәлеген бәян итәргә хәзерлек ул. Фәнни анализ, беренче нәүбәттә, проблемалы укытуның закончалыгыннан чыгып, дәрескә әзерләнү һәм укыту методларын дөрес сайлап алу өчен кирәк. Шушы максаттан укытучы:

а) укучылар өйрәнәчәк материалдан төп төшенчәләрне яки инде билгеле булган әйберләрнең, күренешләрнең, процессларның элек өйрәнелмәгән үзенчәлекләрен һәм билгеләрен аерып күрсәтә. Яңа төшенчәләрне (әйберләрнең, күренешләрнең, процессларның билгеләрен, үзлекләрен) төп яки икенче дәрәҗәле төшенчәләргә бүлә, аларның катлаулылык дәрәҗәсен билгели. Мәсәлән, балалар кыек сөйләмнең нәрсә икәнен беләләр. Бу дәрестә кыек сөйләмнең телдәге роле — алар өчен яңа төшенчә;

б) белемнәрнең структурасын ачыклый һәм иҗади яки хәтергә төшерү юлы белән (репродуктив) үзләштерергә тиешле элементларын һәм аларның үзара бәйләнешен билгели;

в) элек (бу уку елында яки берничә ел элек) өйрәнелгән, ләкин яңа дәрестә кирәк булачак сорауларны алдан ук хәзерли;

г) элек үткәннәргә таянып, укучылар мөстәкыйль рәвештә үзләштерәчәк яңа төшенчәләр белән яңа дәрестә биреләчәк белемнәр арасындагы элемтәне ачыклый;

д) киләчәк дәресләрдә өйрәнеләчәк яңа төшенчәләрне билгели;

е) төшенчәләргә, билгеләмәләргә, кагыйдәләргә, теоремаларга,

законнарга һ. б. биреләчәк формулировкаларның төрле вариантларын алдан әзерләп куя. Мәсәлән, «Кыек сөйләмнең телдәге роле?» яки «Кыек сөйләмне ни өчен кулланалар?» һ. б. ш.

**2. Логик анализ.** Проблемалы дәрескә әзерләнгәндә, укыту материалына логик анализ ясауның әһәмияте аеруча зур, чөнки проблемалы укытканда дәрес бирү процессларының һәм дәреслектәге материалның логик төзелешләре ягыннан кайбер үзенчәлекләре бар.

Логик анализ тагын шуның өчен кирәк, укытучы яңа белемнәрне бәян итү процессында: төшенчә, фикер йөртү, сөземтә кебек логик уйлау формалары белән эш итәргә, логикадан, шулай ук укытуның дидактик чаралары сыйфатында билгеләмәләр, классларга бүлү, индукция һ. б. кебек логик операцияләрдән һәм методлардан турыдан-туры файдаланырга тиеш була.

Белемнәр үзара бәйләнешле билгеле бер эзлеклелектәге система тәшкил иткәнлектән, укучыларга укыту заданиеләрен билгеле бер эзлеклелектә җиткерү яки фактик материалны шул эзлеклелектә бәян итү проблемалы укытуны оештырганда хәлиткеч роль уйный. Эзлеклелекне булдыру түбәндәге принципка нигезләнә: башка материалны белмичә дә үзләштереп була торган материал беренче булып аңлатыла. Беренчесен белми торып аңлашылмаса, ул чагында башта беренчесе аңлатыла, тик шуннан соң гына икенчесен аңлатуга кү-чelә.

Мәсәлән, алдан: «Нинди сөйләм кыек сөйләм дип әйтелә?» — дигән сорау куела. Шуннан соң гына кыек сөйләмнең телдәге роле тикшерелә. Булмаса, кыек сөйләмнең нәрсә икәнен дә белдермичә, аның телдәге роле турында сорау логиканы (фикерләү законым) бозу булыр иде. Белем элементлары арасындагы логик бәйлелекме бозу материалны кыенлаштыруга китерә, аны аңлау һәм үзләштерү мөмкинлеген чикли.

**3. Психологик анализ.** Укыту материалына фәнни һәм логик анализ гына түгел, психологик анализ да ясарга кирәк. Психологик анализның төп максаты түбәндәгеләр:

а) сорауларның, мәсьәләләрнең һ. б. формулировкасында укыту проблемаларының булу-булмавын, укыту заданиеләрен башкарган: чагында, проблемалар барлыкка килү-килмәвен яки аларны укучыларның үзләренең куя алу-алмау мөмкинлеген (ихтималын);

б) проблемалы ситуацияләрнең һәм укыту проблемаларының типларын;

в) материалның эчтәлеге һәм тәкъдим ителәчәк проблемаларны кую алымнары буенча аларның катлаулылык дәрәҗәсен;

г) төп проблеманы хәл итүне җиңеләйтү максаты белән (мөстәкыйль хәл итү һәм укытуны индивидуальләштерү өчен), ярдәмче проблемалар тудыру мөмкинлеген;

д) классның эмоциональ рухын күтәрү, укучыларда теманы үзләштерүгә кызыксыну уяту чараларын ачыклау.

Дәрескә әзерләнгәндә, укытучы класс коллективының яки аерым укучыларның кәефенә тәэсир итүе һәм аларның фикер барышын үзгәртүе ихтимал булган уку ситуацияләрен алдан искә алырга тиеш.

Укыту материалына психологик анализ ясау укытучыга яңа белемнәрне проблемалы үзләштергәндә укучыларның эшчәнлеге белән идарә итү алымнарын ачып бирергә ярдәм итәчәк.

**4. Дидактик анализ.** Материалга дидактик анализ ясау буенча укытучыларыбызның тәҗрибәсе аз түгел. Аның методикасы педагогик әдәбиятта да шактый киң яктыртылган[9]. Шунлыктан без проблемалы дәрескә әзерләнү вакытындагы дидактик анализның асылына гына тукталабыз.

Укыту материалын фәнни, логик һәм психологик анализлаудан алынган нәтиҗәләрдән чыгып, укытучы:

а) дәреснең дидактик максатын ачыклый һәм бурычын билгели;

б) фактик материалның күләмен билгели, проблемалы сораулар, танып-белү бурычлары кую һәм заданиеләр бирү максаты белән, фактик материалны өлешләргә бүлә, кайсы материалга күпме вакыт китәчәген ачыклый;

в) сорауларны, танып-белү бурычларын төркемнәргә берләштерү мөмкинлеген билгели; белемнәрне ныгыту һәм күнекмәләр булдыру өчен, биремнәр системасы сайлап ала, укучылар әйтүе ихтимал булган фараз итүләр һәм гипотезаларның вариантларын чамалый, фән тарихыннан кирәкле мисаллар һәм мәгълүматлар эзләп таба;

г) дәреснең бурычларыннан һәм укучыларның акыл үсеше дәрәҗәсеннән чыгып, кирәкле дидактик материаллар һәм техник чаралар хәзерләп куя, программалаштырылган әсбаплар куллану мөмкинлеген ачыклый;

д) проблемалы ситуация тудыруның методик алымнарын һәм ысулларын, ярдәмче сораулар формасында «әйтел җибәрү»нең вариантларын билгели, укучыларның мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеге процессы белән идарә

[9] Кара: З. И. Романовская. Подготовка учителя к урокам, 220—240 нчы битләр.

итү һәм укытуны индивидуальләштерү максатыннан чыгып, карточкалар (өләшү материаллары), күрсәтмә әсбаплар һ. б. хәзерли. Укучыларның элекке һәм яңа үзләштерелгән белемнәренең ныклыгын ачыклау өчен контроль ясау, кире информация алу алымнарын билгели һ. б.

Дәреснең максатын һәм бурычларын билгеләүнең әһәмияте аеруча зур. Дәрескә әзерләнгәндә укытучы дәреснең һәр этабында укучыларның нәрсәләр эшләячәген, нинди төшенчәләр үзләштерәчәкләрен һәм акыл эшчәнлегенең нинди алымнары хасил булачагын бик төгәл билгеләргә тиеш.

**5. Дәреснең тәрбияви әһәмиятен билгеләү.** Тормыш Л. Н. Толстойның, укыту тәрбиядән башка була алмый, дигән сүзләрен адым саен раслый, һәр дәреснең материалы, укытучының һәрбер сүзе һәм хәрәкәте, дәреснең дидактик җиһазлануы, күрсәтмәлелек һәм укучыларның үзләренең практик эшчәнлеге — болар һәммәсе укучыларга тәрбия бирә.

Дәрес материалына тәрбияви яктан анализ ясауның төп бурычы аның теге яки бу өлеше тәрбия бирәме-юкмы икәнен ачыклауда түгел, бәлки:

а) шәхеснең нинди сыйфатлары, характеры тәрбияләнүен;

б) нинди дәрәҗәдә тәрбияләнүен;

в) дәреснең тәрбияви әһәмиятен ничек көчәйтү мөмкинлеген;

г) укучыларның дөньяга карашларын һәм инануларын булдыруга укыту материалының тәрбияви йогынтысын ничек юнәлтү кирәклеген билгеләүдән гыйбарәт.

Сүз, билгеле, «тәрбия моментлары» турында түгел, бәлки тәрбия процессының өзлексез алып барылуы, аның нәтиҗәлеле-ген дөрес оештыруга һәм дөрес идарә итүгә бәйле булуы турында бара. Укытучы һәр дәрестә укучыларга идея-политик, әхлак, эстетик, атеистик һәм хезмәт тәрбиясе бирү буенча максатка юнәлдерелгән эш алып барырга бурычлы. Бу бурычны тормышка ашыруның тик бер генә юлы бар, ул — дәресне оештыруга фәнни күзлектән карау.

Бер-берсенә капма-каршы булган ике идеология көрәшенең көчәюе шартларында фәнни-техник революция белем нигезләренең фәнни һәм ныклы булуын гына түгел, бәлки алган белемнәрне марксистик-ленинчыл инануга әверелдерү буенча системалы эш алып баруны да таләп итә. Совет мәктәбендә проблемалы укыту процессының асылы әнә шунда.

* * *

Хәзер инде проблемалы укытуны оештыруда укытучының роле турында берничә сүз. Яңа дидактик система буларак, проблемалы укытуны яхшы хәзерлекле укытучы гына гамәлгә кертә, җәмгыятькә файдасы тиярлек <итеп практикада тормышка, ашыра ала.

Традицион укыту вакытында, гамәлдәге дидактик принципларга һәм методик рекомендацияләргә таянып, укытучы теге яки бу дәрәҗәдә нәтиҗәгә ирешә алса да, проблемалы укытуны оештыру аңардан системалы рәвештә иҗади эшләүне таләп итә. Укучының психик халәтен, аның укырга хәзерлек дәрәҗәсен үз вакытында белү, дәрестә проблемалы ситуацияләр һәм укучыларда мөстәкыйль танып-белү эшчәнлегенә стимул тудыра алу, шул эшчәнлек белән оста идарә итү һ. б.— менә болар һәммәсе педагогик интуициянең тәрәккый ителгән булуын да, акыл зирәклеген дә, дәрес барышында фикер агышын бик тиз үзгәртә алуны да, методик осталыкны да, һәм, ниһаять, укытуны фәнни оештыру күнекмәләренә (бусы — иң әһәмиятлесе) ия булуны да таләп итәләр. Проблемалы укытуның уңышлы булуына тик шул чакта гына өметләнергә мөмкин.

Дәреснең төп максаты — югары нәтиҗәгә ирешү, ягъни укучыларның белемнәре, эшли белү осталыклары, күнекмәләре нык булырга, дәрестә алган белемнәр укучыга алга таба адым, аның «микроүсеш»ендә «сикереш» ясарга ярдәм итәргә тиеш.

Укытуда югары нәтиҗәлелеккә бүген яхшы хәзерлеге булган укытучы гына ирешә алуын бер минутка да онытырга ярамый. Бездән моны партиябезнең XXIV съезды карарлары таләп итә.